РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.05.2021 Буа шәһәре № 128/Бк-к

ТР Буа муниципаль районында халыкның социаль
якланмаган катламнарының торак йортларын
планнан тыш тикшерү буенча комиссия төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында халыкның социаль якланмаган катламнарының торак йортларын планнан тыш тикшерү буенча комиссия составы (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында халыкның социаль якланмаган катламнарының торак йортларын планнан тыш тикшерү буенча комиссия турында нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы Л.Р. Шакирҗанов

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 17 маендагы 128/Бк-к номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында халыкның
социаль яклaнмаган катламнарының торак йортларын планнан
тыш тикшерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Садретдинова Лилия Назыйм кызы | - Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, (комиссия рәисе); |
| Гафурова Ләйсән Рафаил кызы | - Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Гармония" халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге " дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры, комиссия секретаре (килештерү буенча); |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Камалова Ләйлә Рөстәм кызы | - Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Буа муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Македонская Наталья Александровна | - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы (килешү буенча); |
| Низамов Динар Марат улы | -Россия Эчке эшләр министрлыгының Буа районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчә инспекторы - полиция майоры (килешү буенча); |
| Садыков Нияз Илшат улы | - Буа муниципаль районы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 8 нче Федераль янгын сүндерү хезмәтенең 111 янгын сүндерү һәм коткару часте башлыгы ( килешү буенча); |
| Фәсхетдинова Айгөл Нәгыйм кызы | - Буа муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаган балаларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча баш белгеч (килешү буенча); |
| ТР Буа муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | - торак пунктка карап (килешү буенча). |

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 17 маендагы 128/Бк-к номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында
халыкның социаль якланмаган катламнарының торак йортларын
планнан тыш тикшерү буенча комиссия турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында халыкның социаль якланмаган катламнарының торак йортларын планнан тыш тикшерү буенча комиссиянең (алга таба - Комиссия) эш тәртибен билгели.

2. Комиссия компетенциясе

2.1. Комиссия Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә халыкның социаль якланмаган катламнары торак йортларын ачыклау буенча чаралар үткәрү максатларында төзелә.

2.2. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законнар белән билгеләнә.

3. Комиссия эшен оештыру

3.1. Комиссия даими эшләүче коллегиаль орган булып тора, аның шәхси составы ТР Буа муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

3.2. Комиссиянең санлы составы 5 кешедән дә ким була алмый.

Комиссия составына дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының тармак бүлекчәләре һәм әлеге органнар һәм оешмалар белән килешү буенча оешмалар вәкилләре кертелергә мөмкин.

3.3. Комиссия эше белән комиссия рәисе җитәкчелек итә.

3.4. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, халыкның социаль якланмаган катламнарының торак йортларын ачыклау буенча чаралар үткәрү датасын һәм вакытын билгели, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча документларга кул куя (раслый), комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.5. Комиссия секретаре комиссия эше өчен кирәкле мәгълүмат соратып ала, комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган оешмаларга халыкның социаль яктан аз тәэмин ителгән катламнарын торак йортларны ачыклау буенча планлаштырылган чаралар турында хәбәр итә, кирәкле документлар әзерли һәм аларның саклanышын тәэмин итә, Комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти.

3.6. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә катнашалар, комиссия эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр, комиссия эше барышында кабул ителә торган документларны имзалыйлар, комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.7. Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.